**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТАКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17,с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.02.2019 ________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Татар Ямалы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе Уставын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Татар-Ямалы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең (алга таба ТР Актаныш муниципаль районының «Татар-Ямалы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ Уставын яңа редакциядә (кушып бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Татар Ямалы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Татар Ямалы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ Уставын теркәгәндә мөрәҗәгать итүче булып чыгыш ясарга, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче районара салым инспекциясендә яңа редакциядә һәм башка үзгәрешләрдә үзгәрешләр кертергә, гаризаны, башка документларны имзаларга, кирәкле гамәлләрне һәм формальлекләрне башкарырга вәкаләт бирергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo-tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru.үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча Башккарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ш.Бариев